ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.11.2019 г. Заинск № 588

**«2020 елга “Зәй муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында»**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 854нче (14.12.2009) карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45нче маддәсенә таянып, Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

## карар бирә:

1. 2020 елга расларга:

“Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә тәгаенләнгән норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Мәгариф идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.Р. Печина
3-27-42

«Зәй муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
башкарма комитетының
12.11.2019г.  № 588
карары белән расланган

**“Зәй муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (бер укучыга елга, сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | өч еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |